ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.04.2023 Баулы шәһәре №101

Баулы муниципаль районы башкарма
комитетының 2016 елның 25 июлендәге
240 номерлы карары белән расланган
Баулы муниципаль районы территориясендә
табигый һәм техноген характердагы
гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен
матди ресурслар резервлары турындагы
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2008 елның 11 июлендәге 488 номерлы карары (2022 елның 14 мартындагы ред.), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен федераль башкарма хакимият органнарының матди ресурслары резервларын булдыру, алардан файдалану һәм тулыландыру кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 25 июлендәге № 1119 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 25 июлендәге 240 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Гомуми нигезләмәләр» I бүлегендә:

1.1. пунктында «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру һәм куллану тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1996 елның 10 ноябрендәге 1340 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Матди ресурслар резервларын булдыру, саклау, файдалану һәм тулыландыру тәртибе» II бүлектә:

2.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар муниципаль резервка продукция җибәрүгә тәэмин итүчеләрне билгеләү «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2.8. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.8. Муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә, аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен Баулы муниципаль районының матди ресурслары файдаланыла. Алар җитәрлек булмаганда, Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органы, республика резервыннан матди ресурслар бүлеп бирү турындагы үтенеч белән, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә мөмкин».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — Д.Л. Бакиров